| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2022 Баулы шәһәре № 61

Баулы шәһәр Советының 2009 елның
16 октябрендәге 115 номерлы карары
белән расланган Баулы муниципаль
районының «Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм
бюджет процессы турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 16 октябрендәге 115 номерлы карары белән (12.12.2019 №124, 29.05.2020 №132, 14.12.2021 №45 карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

13 статьяда:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;»;

30 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Бюджет үтәлешен оештыруны Баулы муниципаль районының Финанс-

бюджет палатасына йөкләргә (килешү буенча).»;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

31 статьяның икенче абзацында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» сүзләрен «Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» сүзләренә алмаштырырга;

33 статьяның беренче абзацында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» сүзләрен «Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» сүзләренә алмаштырырга;

35 статьяның икенче абзацында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» сүзләрен «Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К. Ф. Корбанов